# «...ШИГЫРЬ САНДЫГЫН АЧАРСЫҢ...»

Шагыйрь Мәхмүт Газизовның «Гаҗәеп көн» китабы белән танышу безнең өчен чын мәгънәсендә гаҗәеп көн булды. Ике кечкенә улым белән без «Энергетик» мәдәният сарае каршында оештырылган шигырь бәйрәме кичәсенә бардык. Улларым тере шагыйрьләр, язучыларны үз күзләре белән күрделәр. Мәхмүт Газизов, улларым Илдар һәм Айдарга багышлап 4 юллык шигырь дә язып, «Гаҗәеп көн» дигән китабын бүләк итте. Улларыма китап бик ошады.

Мәхмүт Газизовның «Гаҗәеп көн» исемле шигырьләр китабы гаилә китапханәбезнең түрендә булды. Балалар бакчасында тәрбияләнүче балаларга адресланып язылган бу җыентык. Бала тәрбияләп караган һәркем дә әйтер, аларны тәрбияләү үтә дә җаваплы, савaплы, кирәкле, зур әһәмияткә ия булган эш. Кечкенәләр — алар искиткеч, бик кызыксынучаннар. Алар һәрнәрсәдән могҗиза көтәләр, дөньяны танып белергә омтылышлары гаять зур булган тынгысыз затлар. Безне чолгап алган тирә-юнь алар өчен бик кызыклы. Кечкенә тиктормасларны җәлеп итәрдәй, аларның самими күңелләрен яулардай шигырьләр күп бу китапта. Балалар психологиясен тирән аңлап, тоеп, белеп язылганнар алар. Балаларны яхшы күнекмәләргә, асыл, кирәкле булган сыйфатларга өйрәтер иде бу шигырьләр җае белән, урынын белеп кулланганда. Бу нисбәттән «Гаҗәеп көн» шигыре гаять үзенчәлекле.

«Тышта — бакча өмәсе,  
Эштә дуслар һәммәсе.  
Искәндәргә көрәк бар,  
Кызларга — су, чиләкләр.  
...Туясы килми эштән,  
Керәсе килми тыштан.  
Искәндәр чүп-чарларны  
Җыеп куйды берочтан.  
Өмә бетте, куллар да  
Өлгермәде арырга.»

Балалар рәхәтләнеп уйнаган кебек кенә итеп эшлиләр. Хезмәт кораллары белән эш итәргә өйрәнәләр, су сипкеч белән түтәлләргә су сибәргә, көрәк куллану җаена төшенәләр, түтәлләрне тәрбияләргә, сукмактан гына йөрү хикмәтләренә төшенәләр. Эшне төгәлләү этабы белән дә танышалар;

...Искәндәр чүп-чарларны  
Җыеп куйды берочтан.

Балалар кечкенәдән үк шушы рәвешле эш тәртибе белән танышып, эшләп үссәләр, эшне көе белән башкарсалар, җыйнаклыкка, пөхтәлеккә, әбиләр әйтмешли ыктыматлыкка өйрәнерләр иде.

«Чиста су», «Алма», «Саран малай», «Рогаткалы песиләр», «Ботка» исемле шигырьләре эчтәлекләре белән тәрбияви, кызыклы.

Балаларның зиһеннәрен ачу, яхшырту, зирәклекләрен, тапкырлыкларын арттыру, үстерү, сөйләшкәндә авазларны дөрес әйтү күнекмәләрен үстерү, туган телебезне тагы да яхшырак өйрәнә алу мөмкинлекләре булсын дип тизәйткечләр, табышмаклар да язган әле Мәхмүт абый Газизов.

Бу китапның редакторы танылган балалар шагыйре Рәшит Бәшәр. Рәссамы Илшат Фәррахов.

Китап — укытучыларга, ата-аналарга, балалар бакчасы тәрбиячеләренә менә дигән бүләк инде.

Шагыйрь Мәхмүт абый Газизовка киләчәктә иҗади уңышлар, шатлыклар, ныклы сәламәтлек телим. Нәниләр өчен тагы да матур-матур, кызыклы шигырьләр язар дип ышанасы килә.